ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.08.2024 Олы Кайбыч ав. № 275

«Милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 30 сентябрендәге 409 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 312-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 04 августындагы номерлы 492-ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, муниципаль милектәге җир кишәрлегеннән түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 30 сентябрендәге 409 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.2.1 пунктындагы 11 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гаризаны формаль-логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче һәр кырны электрон рәвештәге кырны тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан тутырылган электрон рәвештәге кырның корректлы булмаса да, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр итү юлы белән сорауның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.»;

2.8.1 пунктының 13 пунктчасында «бакчачылыкны» сүзен «гражданнарның үз

ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып барулары» сүзләренә алмаштырырга;

Административ регламентка 1 нче кушымтаның 16 пунктында «әлеге күчемсез мөлкәт объектлары» сүзләрен «дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге биналар, корылмалар» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе О.Д.Макаровага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров